ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» мая 2026 ел № 135

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы буенча 2026 елга торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен раслау турында

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Бәяләп сату эшчәнлегенә бәйле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына эксперт ярдәмен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 26 декабрендәге 1210 номерлы карары,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү" дәүләт программасын раслау турында" 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары нигезендә, "Бәяләр диапазонын билгеләү турында" 2026 елның 05 февралендәге 23 номерлы "Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге" коммерцияле булмаган партнерлыгының хатын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2026 - 2027 елларга Әгерҗе муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләрне исәпләү өчен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы буенча 2026 елга бер квадрат метрның уртача базар бәясен расларга, 75 000 сум күләмендә.

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 01.01.2026 елда барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкчесе** **И.Х.Салихов**